# КАРАР

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка авыл җирлеге Бутлеровка авыл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

2023 елның 31 октябреннән № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 31 октябрендә узган гражданнар җыенының нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде, түбәндәге сорау буенча «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Бутлеровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Бутлеровка авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан,көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

-Бутлеровка авылы зиратына юлны ремонтлау һәм төзү,

-җирлек эчендәге юлларны карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частләр сатып алу килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

-торак пунктта урамнарны яктыртуны карап тоту (эш өчен түләү һәм килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);

-каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнер мәйданчыгы урнаштыру ( төзелеш материалы сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 111 кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 68 кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:
«ЯКЛЫЙМ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 65 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 3 җыенда катнашучы тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:
1. Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка авыл җирлегендәге Бутлеровка авыл торак пунктында гражданнар җыены булып узды дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга: «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының « Бутлеровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Бутлеровка авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

-Бутлеровка авылы зиратына юлны ремонтлау һәм төзү,

-җирлек эчендәге юлларны карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частләр сатып алу килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

-торак пунктта урамнарны яктыртуны карап тоту (эш өчен түләү һәм килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);

-каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнер мәйданчыгы урнаштыру (төзелеш материалы сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәл Бутлеровка авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә , Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Бутлеровка авыл җирлеге башлыгы И.Л. Хушанова